# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Каратмән торак пунктында

30 нчы октябрь 2023 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Каратмән торак пунктында гражданнар җыены

**Карар кабул итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Каратмән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, студентлардан тыш 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- зиратны төзекләндерү;
- территорияне төзекләндерү (контейнер мәйданчыгы төзү);
- асфальт кисәкчекләре сатып алу

3. Әлеге карарны Олы Җәке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Ф. А. Фәйзуллина